ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ**
11.06.2015

**БОЕРЫК**
№ 156

**Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының «Электр һәм газ белән тәэмин итү буенча коммуналь хезмәтләргә куллану нормативларын билгеләү өчен, бу нормативларны билгеләү ресурслар белән тәэмин итүче оешмалар башлангычы белән эшләнгән очракта, ресурслар белән тәэмин итүче оешмалардан Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетына тапшырыла торган документлар исемлеген һәм эчтәлеген билгеләү турында» 2014 елның 4 декабрендәге 389 санлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясенең аерым законнарына хуҗалык җәмгыятьләренең мөһергә ия булу мәҗбурилеген юкка чыгару өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 6 апрелендәге 82-ФЗ санлы Федераль закон таләпләренә туры китерү максатыннан,
боерам:

1. Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының «Электр һәм газ белән тәэмин итү буенча коммуналь хезмәтләргә куллану нормативларын билгеләү өчен, бу нормативларны билгеләү ресурслар белән тәэмин итүче оешмалар башлангычы белән эшләнгән очракта, ресурслар белән тәэмин итүче оешмалардан Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетына тапшырыла торган документлар исемлеген һәм эчтәлеген билгеләү турында» 2014 елның 4 декабрендәге 389 санлы боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

боерыкның 1 кушымтасы 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Электр белән тәэмин итү буенча коммуналь хезмәтләргә куллану нормативларын билгеләү өчен вәкаләтле органга мөрәҗәгать итүнең сәбәпләре һәм дәлилләре мәҗбүри күрсәтелгән гариза (оешма җитәкчесе имзалаган, мөһере сугылган (мөһергә ия булганда);»;

боерыкның 2 кушымтасы 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Газ белән тәэмин итү буенча коммуналь хезмәтләргә куллану нормативларын билгеләү өчен вәкаләтле органга мөрәҗәгать итүнең сәбәпләре

һәм дәлилләре мәҗбүри күрсәтелгән гариза (оешма җитәкчесе имзалаган, мөһере сугылган (мөһергә ия булганда);».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән соң ун көн узгач үз көченә керә.

Рәис М.Р. Зарипов